**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ДАЧНЫЙ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

422700, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Дачный авылы, Үзәк урамы, 34

**СОВЕТ ДАЧНОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422700, Республика Татарстан, Высокогорский район,
п.Дачное , ул. Центральная, д. 34

тел./факс 8(84365) 78-3-33 e-mail: Dach.Vsg@tatar.ru

---

**КАРАР** | **РЕШЕНИЕ**

**15 ноябрь 2019 ел** | **№ 147**

## Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Дачный авыл җирлеге муниципаль казнасы турында Нигезләмәне раслау турында

Россия Федерациясе Гражданнар кодексының 215 статьясы, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 35 статьясы 10 бүлеге 5 пункты нигезендә, Биектау муниципаль районы Советының 2016 елның 5 нче декабрендәге 124 номерлы Карары белән расланган Татарстан Респбликасы Биектау муниципаль районы Дачный авыл җирлеге муниципаль милкендә булган милек белән идарә итү һәм гамәл кылу тәртибе турында Нигезләмә, “Биектау муниципаль районы Дачный авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставы белән эш йөртеп, Дачный авыл җирлеге Советы,

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Теркәлгән “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Дачный авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге муниципаль казнасы турында Нигезләмәне расларга.
2. Әлеге карарны авыл җирлегенең рәсми стендларында, Биектау муниципаль районы рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru адресы буенча авыл җирлекләре бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).
3. Әлеге карар рәсми рәвештә бастырылып чыкканнан соң (халыкка җиткерелгәннән соң) үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Совет рәисе,
авыл җирлеге башлыгы урынбасары Р.А.Жильцов

Кушымта

Расланган
Татарстан Республикасы
Биектау муниципаль районы
Дачный авыл җирлеге
Советы карары белән
15 ноябрь 2019 ел № 147

**“Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Дачный авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге муниципаль казнасы турында Нигезләмә**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1. “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Дачный авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге муниципаль казнасы турында Нигезләмә (алга таба – Нигезләмә) түбәндәге норматив-хокукый актлар нигезендә эшләнелгән:

1) Россия Федерациясе Конституциясе;

2) Россия Федерациясе Гражданнар кодексы;

3) “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон;

4) 2015 ел 11 нче ноябрендәге 17 номерлы (2016 ел, 10 нчы октябрендәге, 24-1 номерлы, 2017 ел, 07 сентябрендәге, 87 номерлы, 2018 ел, 30 нчы мартындагы, 80 номерлы, 2018 ел, 14 нче сентябрендәге 100 номерлы Совет карары редакциясендә) Совет карары белән кабул ителгән, “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Дачный авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставы;

5) Биектау муниципаль районы Советының 2016 елның 21 нче сентябрендәге 22 номерлы (2018 ел, 15 нче майендагы, 881 номерлы Совет карары редакциясендә) Карары белән расланган Татарстан Респбликасы Биектау мунииципаль районы Дачный авыл җирлеге муниципаль милкендә булган милек белән идарә итү һәм гамәл кылу тәртибе турында Нигезләмә;

6) Россия Федерациясе, Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары, “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Дачный авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге муниципаль норматив хокукый актлары.

2. Әлеге Нигезләмә “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Дачный авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге муниципаль казнасын (алга таба – муниципаль казна) формалаштыруның максатларын, бурычларын, тәртибен, муниципаль казна составына керүче милекнең исәбен алу, идарә итү һәм эш итү тәртибен, аның бөтенлеге һәм максатчан кулланылышын контрольдә тотуны билгели.

## II. Муниципаль казнаны тәшкил итүче муниципаль милекне формалаштыру, исәп алу, идарә итү һәм эш итү максатлары һәм бурычлары

3. Муниципаль казнаны тәшкил итүче муниципаль милекне формалаштыру, исәп алу, идарә итү һәм эш итү максатлары булып торалар:

1) “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Дачный авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге муниципаль казнасының матди-финанс базасын булдыру, саклау һәм ныгыту;

2) “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Дачный авыл җирлеге” муниципаль берәмлегенең икътисади һәм финанс мөстәкыйльлеген һәм социаль-икътисади үсешен тәэмин итү;

3) “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Дачный авыл җирлеге” муниципаль берәмлегенең структурасын һәм составын оптимальләштерү;

4) “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Дачный авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге муниципаль милке объектларын саклау, булдыру һәм арттыру;

5) “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Дачный авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге территориясенә инвестицияләрне җәлеп итү һәм эшмәкәрлек активлыгын арттыру.

4. Муниципаль казнаны тәшкил итүче муниципаль милекне формалаштыру, исәбен алып бару, идарә итү һәм эш итү бурычлары булып тора:

1) муниципаль милекнең һәр объектының һәм аның хәрәкәтенең исәбен алу;

2) муниципаль казнаны тәшкил итүче муниципаль милеккә бәя бирү һәм муниципаль милек хокукына дәүләт теркәве;

3) максатчан билгеләнеше буенча муниципаль казнаны тәшкил итүче муниципаль милекнең сакланышын һәм кулланылышын контрольдә тоту;

4) муниципаль казнаны тәшкил итүче муниципаль милекне файдалануның иң нәтиҗәле ысулларын ачыклау һәм куллану.

## III. Муниципаль казнаның составы

5. Муниципаль казнаны “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Дачный авыл җирлеге” муниципаль берәмлегенең муниципаль унитар предприятиеләре һәм учреждениеләренә хуҗалык итү яки оператив идарә итү хокукында беркетелмәгән “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Дачный авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге бюджет чаралары (алга таба – җирле бюджет) һәм “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Дачный авыл җирлеге” муниципаль берәмлегенең башка муниципаль милке тәшкил итәләр, шул исәптән:

1) кыйммәтле кәгазьләр, акция пакетлары, хуҗалык җәмгыятьләренең устав капиталларында өлешләр;

2) күчемсез милек, шул исәптән җир кишәрлекләре, җир асты кишәрлекләре, торак булмаган биналар, корылмалар, торак фонд объектлары, коммуналь инфраструктура объектлары, җирле әһәмияткә ия булган гомуми кулланылыштагы автомобиль юллары, юл корылмаларын, паркларны, скверларны, урман кишәрлекләре, буалар, сулы карьерлар, Россия Федерациясе законнары нигезендә күчемсез милеккә кертергә мөмкин булган башка обектларны да кертеп;

3) күчемле милек;

4) “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Дачный авыл җирлеге” муниципаль берәмлегенең интеллектуаль милек объеклары, шул исәптән аларга махсус хокукларны да кертеп;

5) гомуми милек хокукында өлешләр;

6) “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Дачный авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге алдында йөкләмәләр;

7) башка милек, шул исәптән Россия Федерациясе законнары нигезендә милек хокуклары.

## IV. Җирле бюджет чаралары

6. Җирле бюджет чаралары муниципаль казнаны тәшкил итүче өлеше буларак, Россия Федерациясе бюджет законнары, Устав нигезендә барлыкка киләләр һәм тотылалар.

7. Әлеге Нигезләмәнең V – VIII бүлекләрендәге гамәлләр җирле бюджет чараларына кагылмыйлар.

## V. Муниципаль казнаны формалаштыру

8. Объектларны муниципаль казнага кертү өчен җирлек булып тора:

1) “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Дачный авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге бюджеты чаралары хисабына милекне булдыру яки алу;

2) “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Дачный авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге муниципаль милкенә дәүләт милкеннән (федераль милектән, Татарстан Республикасы милкеннән), башка муниципаль берәмлекләрнең муниципаль милкеннән милекне тапшыру;

3) “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Дачный авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге муниципаль милкенә юридик һәм физик затлар, шул исәптән шәхси эшмәкәрләр тарафыннан, сату-алу, алыштыру, бирү шартнамәсе нигезендә, васыятьнамәләр нигезендә яисә гамәлдәге законнар белән күз алдында тотылган башка килешүләр нигезендә милекне тапшыру;

4) милекне законлы нигезләрдә (артык, кулланылмый торган яисә билгеләнү буенча кулланылмый торган) муниципаль предприятиеләрнең хуҗалык итүеннән яки муниципаль учреждениеләрнең оператив идарәсеннән алу; милекне муниципаль предприятиеләр һәм муниципаль учреждениеләрнең аларны куллануудан баш тартуы нәтиҗәсендә милекне алу;

5) “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Дачный авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге муниципаль милке хокукын хуҗасыз милеккә, гамәлдәге законнар белән билгеләнгән тәртиптә алу;

6) бетерелә торган муниципаль унитар предпритияләр яки муниципаль учреждениеләрнең кредит бирүчеләре таләпләрен канәгатьләндергәннән соң калган милекне тапшыру;

7) “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Дачный авыл җирлеге” муниципаль берәмлеген муниципаль милеккә, суд карары нигезендә алу вакытының дәвамлылыгы исәбенә алу;

8) “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Дачный авыл җирлеге” муниципаль берәмлеген гамәлдәге законнар белән күз алдында тотылган хосусыйлаштыру килешүләрен бетерү нәтиҗәсендә муниципаль милеккә алу;

9) “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Дачный авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге муниципаль милкенә башка законлы нигезләр нигезендә керү.

9. Муниципаль казна милкен формалаштыру һәм аларны тоту һәм исәбен алу буенча барлык кирәкле чараларны финанслау “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Дачный авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге бюджеты чаралары хисабына башкарыла.

10. Муниципаль казна объектлары беренчел хисапка беренчел кыйммәт (баланс) буенча кабул ителәләр. Беренчел кыйммәтне ачыклау мөмкин булмаган очракта, объект кыйммәтенә бәйсез бәя уздырыла.

11. Объектларны муниципаль казнадан чыгару өчен җирлек булып торалар:

1) милекне булдырыла торган муниципаль унитар предприятиеләрнең устав капиталларына яисә эшчәнлек алып баручы муниципаль унитар предприятиеләрнең хуҗалык карамагына кертү;

2) милекне булдырыла торган яки эшчәнлек алып баручы учреждениеләргә оператив идарә итүгә тапшыру;

3) милекне кертемнәр сыйфатында хуҗалык җәмгыятьләренә кертү;

4) милекне читләштерү (шул исәптән хосусыйлаштыру);

5) күчемсез милек өчен түләттерү белән мөрәҗәгать (шул исәптән залог предметы булган);

6) милеккә зарар салу нәтиҗәсендә килеп туган югалтулар, шулай ук аны юк итү яисә табигать бәла-казалары һәм башка табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр вакытында китерелгән зыян;

7) милекне аның тулы физик һәм мораль тузуы белән бәйле рәвештә расходка чыгару;

8) гамәлдәге законнар белән күз алдында тотылган башка гамәлләр кылу.

12. Объектларны муниципаль милек составына кертү һәм аларны муниципаль казна составыннан чыгару әлеге Нигезләмәнең 14 пунктында күрсәтелгән вәкаләтле органнар тарафыннан, “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Дачный авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органнары карарлары нигезендә, әлеге Нигезләмәнең 8,11 пунктларында күрсәтелгән нигезләр буенча тормышка ашырыла.

### VI. Муниципаль казна объектларын исәпкә алу

13. Муниципаь казнаны тәшкил итүче милек “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Дачный авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге муниципаль милке реестрында (алга таба – реестр исәбе) исәпкә алынырга һәм бюджет исәбе уздырылырга тиеш.

14. Муниципаль казна милкенең реестр исәбе Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан тормышка ашырыла:

а) муниципаль казнада булган торак фонд объектларына, шулай ук торак фонд объектларын җиһазлау өчен билгеләнгән күчемле милеккә карата;

б) “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Дачный авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге муниципаль милкендә булган милеккә ия булу,

куллану һәм идарә итү өлкәсендә җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү буенча,
- муниципаль казнада булган башка күчемле һәм күчемсез милеккә карата.

Муниципаль казна милкенең реестр исәбе “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Дачный авыл җирлеге” муниципаль берәмлегенең муниципаль милек реестрының тиешле бүлегенә милек турында мәгълүматларны “Җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль милек реестрын алып бару Тәртибен раслау турында”, 2011 елның 30 августындагы 424 номерлы Россия Федерациясе Икътисади үсеш министрлыгы боерыгы нигезендә, кертү юлы белән тормышка ашырыла.

Бюджет хисабы “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Дачный авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге муниципаль милкендә булган милеккә ия булу, куллану һәм идарә итү өлкәсендә мәсьәләләрне хәл итү буенча, Россия Федерациясенең бухгалтерлык хисабы турында закон таләпләре нигезендә, бухгалтерлык хисабы өлкәсендә вәкаләтле башкарма хакимиятнең федераль органы билгеләгән тәртиптә, муниципаль казнаны тәшкил иткән күчемсез милек, күчемле милек, китереп чыгармаган активлар һәм матди запаслар киселешендәге милек объектлары исәбенең аерым счетында (финанс булмаган активлар) тормышка ашырыла. Муниципаль казнаның милек объектларына балanска куелган датадан амортизация саналмый, аларны кабаттан бәүләү уздырылмый, гамәлдә булган Россия Федерациясе законнарында билгеләнгәннәрдән кала.

“Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Дачный авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге милкендә булган күчемле милек, “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Дачный авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге муниципаль милке реестрында әгәр дә аның бәясе 10000 (Ун мең) сумнан артса, исәптә торырга тиеш,.

Акцияләр, хуҗалык җәмгыятьләре яки ширкәтләре устав капиталларында өлешләр (кертемнәр) рәвешендәге милек, китапханә фондлары объектлары, “Коммерцияле булмаган оешмалар турында”, 1996 елның 12 нче гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль закон, “Автоном учреждениеләр турында”, 2006 елның 3 нче ноябрендәге 174-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә билгеләнгән, автоном һәм бюджет учреждениеләренә беркетлегән аеруча да кыйммәтле күчемле милек, “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Дачный авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге муниципаль милке реестрында аның кыйммәтенә карамыйча исәпкә алынырга тиеш.

15. Муниципаль казнаны тәшкил итүче муниципаль милек, милек хокукында “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Дачный авыл җирлеге” муниципаль берәмлегенә карый һәм җирле үзидарә органнары һәм юридик затлар балансында төп яки әйләнеш чаралары сыйфатында күрсәтелергә тиеш түгел.

16. Муниципаль казна милкенә муниципаль милек хокукын раслаучы документлар булып, күчемсез милеккә “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Дачный авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге муниципаль милке реестрыннан өземтә, Бердәм дәхләт күчемсез милек реестрыннан өземтә, “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Дачный авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге муниципаль милкен дәүләт теркәве турында шаһәдәтнамә тора.

17. Муниципаль милекне тәшкил итүче милек ышанычлы идарә итүгә, залогка, арендага, түләүсез файдалануга, хуҗалык алып баруына, оператив идарәгә тапшырылганда, аны алга таба исәпкә алганда билгеле предпритиеләр, учреждениеләр һәм башка оешмаларның бухгалтер хисабында гамәлдәге законнар нигезендә күрсәтелергә тиешле.

18. Муниципаль милекне тәшкил итүче объектларны арендага, түләүсез файдалануга, ышанычлы идарә итүгә концессион килешүләр буенча тапшырганда, күрсәтелгән объектларны муниципаль казна составыннан чыгаруны күз алдында тотмый.

## VII. Муниципаль казна объектлары белән идарә итү

19. Муниципаль казнаны тәшкил итүче объектлар белән идарә итү һәм эш алып бару Биектау муниципаль районы Советының 2016 елның 09 нчы сентябрендәге 22 номерлы Карары (2018 елның 15 нче маендагы 88 номерлы карар редакциясендә) белән расланган Татарстан Республикасы Биектау мунииципаль районы Дачный авыл җирлеге муниципаль милкендә булган милек белән идарә итү һәм гамәл кылу тәртибе турында Нигезләмә нигезендә тормышка ашырыла.

20. Муниципаль казна составына керүче милек, гамәлдәге законнар белән күз алдында тотылган очракларда базар бәяләмәсе уздырылырга тиеш.

21. Муниципаль казна милкен кулланудан кергән керемнәр тулы күләмдә “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Дачный авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге бюджетына кертелергә тиеш.

## VIII. Муниципаль казна объектларының сакланышын һәм максатчан кулланылышын контрольдә тоту

22. Идарә итү һәм (яки) куллану өчен юридик һәм физик затларга бирелмәгән муниципаль казна объектларын карап тоту һәм эксплуатацияләү, милекнең техник инвентаризациясе һәм паспортизациясе, муниципаль казна составына керүче күчемсез милеккә муниципаль милек хокукына бәя бирү һәм дәүләт теркәве Дачный авыл җирлеге Башкарма комитеты тарафыннан “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Дачный авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге бюджеты чаралары хисабына тормышка ашырыла.

23. Идарә итү һәм (яки) куллану өчен юридик һәм физик затларга бирелгән муниципаль казна объектларының сакланышын һәм максатчан кулланылышын контрольдә тоту, шулай ук әлеге затларны тапшырылган объектларны тиешенчә кулланмаган өчен җаваплылыкка тарту Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Контроль-хисап палатасы тарафыннан объектларны тапшыру турында төзелгән шартнамәләр шартлары нигезендә тормышка ашырыла. Контроль барышында Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Контроль-хисап палатасы тапшырылган объектларның халәтен, объектларны тапшыру турында шартнамцлцр шартларын тотуны тикшерүне тормышка ашыралар.

24. Муниципаль казна милкенең сакланышын тәэмин итү өчен милекне иминиятләү, аны куллануның һәм саклауның махсус режимы билгеләнү, шулай ук аны саклауга куюга тапшыру мөмкин.

25. Муниципаль казна объектларын тапшыру срогына аларны карап тоту һәм очраклы рәвештә һәлакәт булу куркынычы кулланучыга күчә һәм объектны тапшыру турында шартнамә таләпләре белән билгеләнә. Муниципаль казна объектларында шартнамә йөкләмәләре булмаган вакытта очракла рәвештә һәлакәт булу куркынычы йөкләмәсен "Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Дачный авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге йөртә.

## IX. Муниципаль казна милкен түләттерүгә мөрәҗәгать

26. "Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Дачный авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге үзенең йөкләмәләре буенча акчалар һәм муниципаль казна милке составына керүче башка милек белән милек җаваплылыгы йөртәләр.

27. "Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Дачный авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенә юнәлдерелгән милек таләпләре иң беренче чиратта җирле бюджет чаралары хисабына, аннан соң муниципаль казна милке составына керүче башка милек хисабына канәгатьләндерелергә тиеш.

## X. Йомгаклау нигезләмәләре

28. Әлеге Нигезләмәне үтәмәгән яки тиешенчә үтәмәгән өчен вазыйфаи затлар гамәлдәге Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылык йөртәләр.